КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 март г.Казань № 277

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 28 сентябрь, 875 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 май, 398 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«икенче категориядәге заявка бирүчеләр – Гомумроссия классификаторының B, G, K, L, O, U бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручылардан һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2022 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел,

10 февраль, 108 нче карары белән расланган 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2022 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә кергәннәрдән тыш, Гомумроссия классификаторының B, G, K, L, O, U бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручылардан һәм (яки) инвестиция проектларын тормышка ашыруга кредит шартнамәсе булганнардан тыш, Гомумроссия классификаторының B, G, K, L, O, U бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручылардан тыш, экспортка юнәлтелгән субъектлар, һәм (яки) идарәче компанияләр, һәм (яки) резидентлар булган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары;»;

1.6 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кредит шартнамәләрен рефинанслауга, башка кредит шартнамәләре яки заявка составында бирелгән кредит шартнамәсе акчасы исәбеннән кредит шартнамәсе буенча бурычны каплауга.»;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердщм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

2.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Заявка бирүче түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия фондына Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең 2021 елның 15 апрелендәге 103п номерлы карары белән расланган «Иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар (СЗВ-М)» формасы буенча белешмә мәгълүматлар (алга таба – иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар) бирү бурычын башкара.»;

3.1 пунктта:

беренче абзацта «заявка бирүче» сүзләре алдына «беренче яки икенче категориядәге» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«салым органының заявка бирү датасына кадәр кимендә биш көннән дә иртәрәк булмаган вакытта Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисапларның торышы турында белешмә кәгазьләре формаларын, аларны тутыру тәртибен һәм белешмә кәгазьләрен электрон рәвештә бирү форматларын раслау хакында» 2016 елның 28 декабрендәге ММВ-7-17/722@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча оешмаларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар буенча исәп-хисаплары торышы турында белешмә кәгазен.»;

3.2 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

3.3 пунктта татар текстында «резидент» сүзе алдына «икенче категориядәге заявка бирүче –» сүзләрен өстәргә;

3.4 пунктта татар текстында «экспортка юнәлтелгән субъект» сүзләреннән соң «икенче категориядәге заявка бирүче» сүзләрен өстәргә;

3.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2022 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 10 февраль, 108 нче карары белән расланган 2020 – 2022 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2022 елга өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә керә торган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын «үстерү» чараларында катнашырга рөхсәт бирелгән икенче категориядәге заявка бирүчеләр әлеге Тәртипнең 3.1 нче пунктында күрсәтелгән документларга өстәмә рәвештә вәкаләтле органның тиешле боерыгы белән расланган сатып алуларны, товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне башкарганда тәэмин итүчеләр (башкаручылар, подрядчылар) буларак үстерүне стимуллаштыру максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс, мөлкәт, мәгълүмат, маркетинг һәм башка ярдәм күрсәтү буенча төбәк квалификация комиссиясе утырышы беркетмәсеннән өземтә тапшырырга хокуклы.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Заявкаларны кабул итү вәкаләтле оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган бердәм порталда һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында, заявкалар кабул ителә башлау көненә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

сайлап алуны үткәрү срокларын;

вәкаләтле оешманың исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 5.4 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә заявка бирүчеләргә карата таләпләрне һәм заявка бирүченең әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен аның тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм әлеге Тәртипнең 3.1 – 3.8 пунктлары нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 4.2 – 4.6 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

заявка бирүчеләргә сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләрен бердәм порталда, шулай ук вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруның сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган датасын;

әлеге критерийлардан чыгып сайлап алына торган, субсидия алу хокукына ия булган заявка бирүчеләрне сайлап алу критерийларын.»;

5.4 пунктта «алтынчы» сүзен «өченче» сүзенә алмаштырырга;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Субсидия алучы вәкаләтле оешмага, килешү төзелгән айдан соң килә торган өченче айга иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар күчермәләрен (пенсия фонды органнарының хисаплылыкны кабул итү турындагы билгесе белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон төрдәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турында документлар белән бирелә) теркәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык кертә. Субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турындагы хисаплылык субсидия алучы тарафыннан, хисап чоры тәмамланган көннән соң килә торган 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле оешмага кәгазьдә тапшырыла. Хисап чоры – килешү төзегән айдан соң килә торган өченче ай.»;

5.6 пунктта:

дүртенче абзацта «субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «мәҗбүри» сүзен төшереп калдырырга;

Тәртипкә 5 нче кушымтада:

уникенче абзацта «заявка бирү көненә» сүзләрен төшереп калдырырга;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия фондына «Россия Федерациясе Пенсия фонды Идарәсенең 2021 елның 15 апрелендәге 103п номерлы карары белән расланган «Иминләштерелгән затлар турында белешмә мәгълүматлар (СЗВ-М)» формасы буенча белешмә мәгълүматлар бирү бурычын башкара.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин